# КАРАР
## Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Иске Барыш авыл җирлегенең Кыртапа авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

03 нче декабрь 2020 ел № 2

“Россия Федерациясендә җирле узидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 121-ФЗ номерлы Федераль законнын 25,1, 56 статьялары, “Татарстан Республикасында җирле узидарә турында” 2004 елнын 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2020 нче елның 03 нче декабрендә булып узган гражданнар җыены нәтиҗәләре нигезендә түбәндәге сорау буенча беркетмә төзелде: «2021 елда Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Иске Барыш авыл җирлеге Кыртапа торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән (Иске Барыш авыл җирлеге территориясендә яшәмәүче һәм көндезге формада белем алучы студентлардан тыш) 600 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм җыелган акчаларны, җирле әһәмияттәге мәсьәләләр буенча түбәндә язылган эшләрне хәл итүгә куллану белән килешәсезме:

1)Кыртапа торак пунктында Яшьләр урамы буенча вак таш җәелгән юлларны ремонтлау (сатып алу, ташу, вак таш җәю, эш өчен түләү);

2)Кыртапа торак пунктында урамнарны яктырту объектларын карап тоту (лампалар, энергия саклаучы яктырткычлар, электр товарлары сатып алу);

3)Кыртапа торак пунктында юлларны кардан чистарту, грейдерлау (ягулык-майлау материаллары, фронталь төягеч һәм бульдозер отвалы трактор өчен запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);

4)Кыртапа торак пунктында җәйге чорда территорияне чабу (ягулык-майлау материаллары, КРН-2,1 Б ротацион чапкычлы трактор өчен запас частьләр сатып алу , килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);

5)Кыртапа торак пунктында су башнясы территориясен төзекләндерү (төзелеш материаллары сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү)».

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 116 кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 60 кеше тавыш бирүдә катнашкан.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде::

«Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы 60 кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен җыенда катнашучы 0 тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте**:**

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Иске Барыш авыл җирлегенә керүче Кыртапа авылы халык җыенын узган дип танырга, халык җыены нәтиҗәләрен дөрес дип санарга.

2. 2021 елда Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Иске Барыш авыл җирлеге Кыртапа торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән (Иске Барыш авыл җирлеге территориясендә яшәмәүче һәм көндезге формада белем алучы студентлардан тыш) 600 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм җыелган акчаларны, җирле әһәмияттәге мәсьәләләр буенча түбәндә язылган эшләрне хәл итүгә куллану белән килешәсезме:

1)Кыртапа торак пунктында Яшьләр урамы буенча вак таш җәелгән юлларны ремонтлау (сатып алу, ташу, вак таш җәю, эш өчен түләү);

2)Кыртапа торак пунктында урамнарны яктырту объектларын карап тоту (лампалар, энергия саклаучы яктырткычлар, электр товарлары сатып алу);

3)Кыртапа торак пунктында юлларны кардан чистарту, грейдерлау (ягулык-майлау материаллары, фронталь төягеч һәм бульдозер отвалы трактор өчен запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);

4)Кыртапа торак пунктында җәйге чорда территорияне чабу (ягулык-майлау материаллары, КРН-2,1 Б ротацион чапкычлы трактор өчен запас частьләр сатып алу , килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);

5)Кыртапа торак пунктында су башнясы территориясен төзекләндерү (төзелеш материаллары сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү)».

4. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында игълан итәргә:

- ТР, Кама Тамагы районы, Кыртапа авылы, Мәктәп урамы, 10 йорт, шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

Халык җыенында рәислек итүче ,
Татарстан Республикасы Кама
Тамагы муниципаль районы
Иске Барыш авыл җирлеге
башлыгы: И.Р.Җиһаншин